**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 15 августындагы 3366 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 9 апрелендәге 1412 номерлы «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 79 еллыгын бәйрәм итүгә, Россия көнен, Татарстан Республикасы көнен һәм Казан шәһәре көнен, Яңа ел бәйрәме чараларын, Бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 138 ел тулуга багышланган, шулай ук «Җиңү варислары»VII ачык хәрби-спорт җыеннарын ачу тантанасын, «Казан марафоны – 2024» халыкара җиңел атлетика чарасын әзерләү һәм үткәрү вакытында Казан шәһәренең автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Региональ яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә:

1. **Карар бирәм**:

1.1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 9 апрелендәге 1412 номерлы «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 79 еллыгын бәйрәм итүгә, Россия көнен, Татарстан Республикасы көнен һәм Казан шәһәре көнен, Яңа ел бәйрәме чараларын, Бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 138 ел тулуга багышланган, шулай ук «Җиңү варислары» VII ачык хәрби-спорт җыеннарын ачу тантанасын, «Казан марафоны – 2024» халыкара җиңел атлетика чарасын әзерләү һәм үткәрү вакытында Казан шәһәренең автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.1. 3 номерлы кушымтада 7 пунктта «28.08.2024, 20.00 сәгатьтән 31.08.2024, 11.00 сәгатькә кадәр» дигән сүзләрне «23.08.2024, 22.00 сәгатән 31.08.2024, 11.00 сәгатькә кадәр (кирәк булганда)» сүзләренә алмаштырырга;

1.1.2. 3 номерлы кушымтаның 9 пунктында:

1.1.2.1. «24.08.2024, 07.00 сәгатьтән 31.08.2024,18.00 сәгатькә кадәр» сүзләрен «22.08.2024, 07.00 сәгатьтән 31.08.2024, 18.00 сәгатькә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

1.1.2.2. «Кремль урамы (Чернышевский урамыннан Беренче Май мәйданына кадәр), шул исәптән Иванов Авышлыгыннан Профсоюз урамына кадәр» сүзләрен «Кремль урамы (Чернышевский урамыннан Беренче Май мәйданына кадәр), Беренче Май мәйданыннан Астрономия урамына кадәр (шул исәптән Иванов Авышлыгы)» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм**:

2.1. Казан шәһәре Думасы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтәләр бүлегенә (В.А.Казанцев) Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 9 апрелендәге 1412 номерлы «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 79 еллыгын бәйрәм итүгә, Россия көнен, Татарстан Республикасы көнен һәм Казан шәһәре көнен, Яңа ел бәйрәме чараларын, Бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 138 ел тулуга багышланган, шулай ук «Җиңү варислары» VII ачык хәрби-спорт җыеннарын ачу тантанасын, «Казан марафоны – 2024» халыкара җиңел атлетика чарасын әзерләү һәм үткәрү вакытында Казан шәһәренең автомобиль юллары буйлап транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә;

2.2. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Н.Д.Закиров) әлеге карар нигезендә җәмәгать тәртибен саклауны оештырырга, Казан шәһәренең урам-юл челтәре участокларында юл хәрәкәте иминлеген саклауны тикшереп торуны һәм күрсәтмә-җайга салу гамәлләрен башкаруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**